**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел, 5 август** **№ 125**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 13 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 66 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Салым кодексы, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы" муниципаль берәмлеге Советы карар кылды:

1. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы" муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 13нче ноябрендәге "Җир салымы турында"гы 66 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,23 % ».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә, әмма 2020 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы, Совет ур., 11нче йорт, җирле үзидарә бинасы;

- шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы, К.Маркс ур., 105нче йорт, китапханә, уку залы, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы”
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
“Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы”
муниципаль берәмлеге Советы рәисе В.П. Сороковнин